Дәрес темасы:. Кыш билгеләре

Максат: 1. “Кыш” темасына караган лексиканы үзләштерү

2. Укучыларның тыңлап аңлау, диалогик һәм монологик сөйләм, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

3. Сәламәт яшәү рәвеше, дуслык хисе тәрбияләү.

Көтелгән нәтиҗәләр.
Предметара: сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерү; бер-береңә игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү шартлары тудыру.
Шәхескә кагылышлы: укучыларның үз эшлчәнлеген оештыра белүе.
Универсаль уку гамәлләре формалаштыру.
Регулятив: эшчәнлекне планлаштыра, үз алдыңа максат куя белү, нәтиҗә ясау.
Танып-белү: дәрестә ориентлаша белү, төрле биремнәр үтәү, проблема кую һәм аны чишү.
Шәхси: кыенлыклардан чыгу юлларын эзләү; үз мөмкинлекләреңне бәяләү.
Коммуникатив: үз фикереңне җиткерә, башкаларны тыңлый белү; диалогта, әңгәмәдә катнашу осталыгын үстерү.
Дәрес тибы: белем һәм күнекмәләрне ныгыту.
Эш формалары: фронталь, индивидуаль, парлап эшләү, группалап эшләү.
Җаһазлау: Р.З.Хәйдәрова. “Татар теле һәм уку китабы”: рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 4нче сыйныфы өчен дәреслек, компьютер, кышкы билгеләр турында рәсемнәр, карточкалар.

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

1. Дәресне оештыру.

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

Хәерле иртә, укучылар!
Хәерле иртә күзләремә!
Хәерле иртә кулларыма!
Хәерле иртә үземә!
Хәерле иртә дусларыма!

– Сыйныфта кем дежур? (Сыйныфта мин Новикова Элина дежур, бүген сыйныфта барсыда бар.Бүген егерме алтынчы ноябрь, атнаның 5 көне, җомга.

– *(Һава торышы музыкасы яңгырый)*

- Ә хәзер һава торышын тыңлап үтегез. Урамда салкын,температура минус 8 , минус 10 градус .Кар ява,төньяктан салкын җил исә. Юлларда бозлавык,сак булыгыз.Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

-Гәдәттәгечә дәресебезне “репортёр булырга” телим уеныннан башлыйбыз
-Бүген кем репортёр булырга тели?
(Укучы чыга)
-Рәхим ит
(Репортёр сораулар бирә)
-Маргарита сиңа нинди ел фасылы ошый? Ни өчен?
-*(Миңа яз ел фасылы ошый,чөнки җылы яктан кошлар кайта)*
-Артём сиңа нинди ел фасылы ошый? Ни өчен?
-*(Миңа җәй ел фасылы ошый,чөнки җәйге каникуллар була)*
Эвелина сиңа нинди ел фасылы ошый? Ни өчен?
-*(Миңа көз ел фасылы ошый,чөнки яфраклар коела)*
Әнисә сиңа нинди ел фасылы ошый? Ни өчен?
-*(Миңа кыш ел фасылы ошый,чөнки яңа ел бәйрәме була)*

II. Актуальләштерү
Фонетик зарядка
1.*(Буран тавышы ишетелә)*
-Укучылар ,нинди авазлар ишетәбез?(-БУ)
-Бу нәрсә?(*Буран)*
-Буран нинди?(*Буран көчле)*
- Көчле буран нишли?(*Көчле буран улый). Укытучы тактадагы буран рәсемен борып куя*
2. *(Кар шыгырдый)*
-Нинди авазлар ишетәбез?(-*шыгыр,шыгыр)*
Бу нәрсә?(*Кар)*
-Кар нишли? *(Ява)*
-Нинди кар ява? *(Ак кар ява) Укытучы тактадагы кар ява рәсемен борып куя*
3 *(Җил исә тавышы)*
-Укучылар ,нинди авазлар ишетәбез?(-Ж)
-Бу нәрсә?(*Җил)*
Җил нишли?(*Җил исә)*
- Нинди җил исә?(*Салкын җил исә). Укытучы тактадагы җил исә рәсемен борып куя*

III. Уку мәсьәләсен кую
Ишекне шакыйлар, укытучы барып посылка ала

-Укучылар дәрес башланды,барабызда монда,кемнер ишек шакый,барып карый әле.
-Укучылар, карагыз әле, безгә хат ташучы посылка алып килде, әйдәгез аны ачып карыйк әле. Артем, миңа булыш әле? (*бергә ачабыз*) ***(тылсымлы музыка уйный)***
-Укучылар, монда хат бар, әйдәгез башта хатны ачып укыйк *(тылсымлы музыка уйный)*
(Язу укыла: “ Исәнмесез, кадерле дусларым! Сезгә Кыш Бабагыз хат яза. Минем табышмакларга дөрес итеп җавап бирегез. Һәрбер дөрес җавапка үземнең кар бөртекләремне бирәм. Уңышлар сезгә!”)
- Мин сезгә бу кар бөртекләрен бүген һәр дөрес җавап өчен биреп барырмын. Шуңа күрә актив эшләвегезне сорыйм.Игътибар белән тыңлагыз :
Табышмакларларга җавап бирү
1.Тәңгә карлар сибелгән
Җир ап-акка күмелгән.
Чыршы,каен,имән, нарат
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак ?(Кыш)

2.Оча- юк канатлары,
Чаба- юк аяклары,
Тышта булса өелә,
Өйгә керсә,җәелә (Кар)

4.Утта янмый, суда батмый. (Боз)

5. Үкерә дә,котыра,
Бөтен җирне тутыра (Буран)

- Табышмаклар нәрсә турында ?
  Укучылар җавабы:
- Табышмаклар кыш, кыш билгеләре турында
- •Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?

Укучылар җавабы(Кыш,кыш билгеләре)
- Әйе, без дәрестә кыш билгеләре турында сөйләшербез.
- Дәрескә без бүген нинди максат куябыз? (Максат билгеләү)

Кыш билгеләре турында сөйлибез ,сүзләр өйрәнәбез,укыйбыз

IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1.Дәрескә кирәкле лексика белән танышу. (СҮЗЛЕК ЭШЕ)

–Укучылар, тактага игътибар итегез, бу сүзләрне укып карыйк әле Дәрескә кирәкле сүзләрне кабатлап алыйк әле.

Туңды *(Мин бик туңдым, укытучы туңганын күрсәтә)*

-Нәрсә туңа?(Су туңа)

Каплады

- Нәрсәне каплады*(Җирне каплады)*
- Нәрсә каплады *(Боз каплады)*

-Сүзлек дәфтәрләрен ачып, бү сүзләрне язып куябыз

2. -Кыш билгеләрен рәсемнәр белән тоташтырыгыз (*интерактив бирем) Сайтка керү леонингапс*

- Бик яхшы, укучылар. Барыгыз да кыш билгеләрен дөрес итеп рәсемнәр белән тоташтырдыгыз

3.- Парларда эшләп алабыз. Сезнең өстәлләрегездә биремнәр бар. Беренче бирем, сүзләргә төшеп калган хәрефләрне куярга. Икенче бирем, тестан дөрес вариантны табарга. Өченче бирем, җөмләләргә төшеп калган сүзләрне куярга

Ял минуты

7.-Укычылар, әйдәгез әле рәсемнәргә карап бер-беребезгә сораулар бирек (*Укучылар кышкы билгеләр рәсеме буенча диалог төзиләр.)*

- Ситуатив күнегүләр аша алган белемнәрне тикшерү.

- Спроси у друга, на улице сегодня какая погода?

-Бүген урамда нинди һава торышы?(Бүген урамда салкын,кар ява)

-Спроси у друга, какие признаки зимы он знает?

- Син нинди кыш билгеләрен беләсен?(Кар ява , салкын, салкын җил исә,көчле буранар була, елгада боз ката,җир ап- ак була.)

- Спроси у друга, нравится ли ей зима?

-Синә кыш ошыймы?(Әйе, миңа кыш ошый)

- Узнай у друга,снег идет ли?

- Кар явамы?(Эйе,кар ява)

V Рефлексия

Төркемләрдә эш

-Төркемнәрдә иҗади эш эшләп алыйк .Ак кәгазь битләренә конверттагы кыш билгеләренә караган рәсемнәрне сайлап алып ябыштырасыз һәм рәсем астына җөмләләр язып куябыз.*(Ясап бетергәч, такта янына чыгыз үзләре эшләгән эшне яклыйлар)*

2. Үзбәя бирү.

-